Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Тынычлык, Нагорная, Комсомол,
Пионер урамнары гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

17 октябрь, 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Тынычлык, Нагорная, Комсомол, Пионер урамнары гражданнарының 2024 елның 17 октябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 121 (йөз егерме бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 62 (алтмыш ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 62 (алтмыш ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2025 елда Иске Шигали авылы Тынычлык, Нагорная, Комсомол, Пионер урамнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тынычлык ур., Нагорная ур., Комсомольская ур., Пионерская ур.)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШИГАЛЕЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * СОВЕТ ШИГАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1633900987